| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Менделеевский муниципальный район<br>Глава Брюшлинского сельского поселения | Татарстан Республикасы<br>Менделевск муниципаль районы<br>Бөрешле авыл җирлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ<br>11.11.2025 | КАРАР<br>№ 4 |

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Башлыгы

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 21 ноябре 17.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Бөрешле авылы, Елга аръягы урамы, 14 йорт адресы буенча урнашкан Бөрешле авыл мәдәният йортында гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

“2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, 18 яшькә кадәрге балаларны тәрбияләүче ялгыз аналардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә срокны хезмәткә чакырылганнардан, 80 яшькә җиткән һәм өлкәнрәк затлардан тыш, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Бөрешле авылында вак таш белән капланган юлларда чокырларны ремонтлау; Бөрешле авылында юлларны кардан чистарту);

2) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка

җайланмаларны ремонтлау (Бөрешле авылында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Бөрешле авылында территорияне чабу)?

«ӘЙЕ»　　　　　　　　　　　　　«ЮК»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Бөрешле авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

Бөрешле авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　Л.А. Смирнова